**КАРАР № 55**

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Советы утырышы

29 август 2022 ел                                                   Түбән Бәрәскә авылы

**«Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Түбән Бәрәскә авыл җирлегендә иҗтимагый тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында"гы 2018 елның 15 декабрендәге 92 номерлы карарга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында (14.05.2021 ел карары редакциясендә)**

2021 елның 11 июнендәге 191-ФЗ номерлы «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы Федераль закон нигезендә, 2022 елның 29 июлендәге 02-08-02/Прдп234-22-20920010 номерлы Әтнә районы прокуратурасы протесты буенча фикер алышканнан соң, Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Советы карар итте:

1.2018 елның 15 декабрендәге 92 номерлы карары белән расланган (14.05.2021 ел карары редакциясендә) Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Түбән Бәрәскә авыл җирлегендә иҗтимагый тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәгә 1 нче кушымта нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.

2. Әлеге карарны Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб–адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru веб–адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җавапчылыгымда калдырам.

Әтнә муниципаль районы
Түбән Бәрәскә авыл җирлеге башлыгы                    А.В.Фатыхова

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Советының 2022 елнын 29 августындагы 55 нче номерлы карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Түбән Бәрәскә авыл җирлегендә иҗтимагый тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр (14.05.2021 елгы карар редакциясендә)

**7 статьяның 4 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:**

Иҗтимагый сөйләшүләрдә яки җәмәгать тыңлауларында катнашучылар мондый проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертергә хокуклы:

1) рәсми сайт яки мәгълүмат системалары аша (җәмәгать фикер алышулары булган очракта);
2) иҗтимагый тыңлауларда катнашучыларның җыелышын яисә җыелышларын уздыру барышында язма яисә телдән (иҗтимагый тыңлаулар үткәрелгән очракта);
3) иҗтимагый фикер алышулар яисә җәмәгать тыңлаулар оештыручы адресына язма рәвештә яисә электрон документ рәвешендә.